# * 7нче сыйныфта туган тел дәресе

***Унсигезенче октябрь, 2018нче ел***

# БИЛГЕЛЕ БЕР КАГЫЙДӘГӘ ТАЯНЫП, ТӨРКЕМНӘРГӘ БҮЛЕГЕЗ


*Ручка, китап, дәфтәр һәм карандаш; кибеттә очраштык; курдем-танымадым; зәңгәр, сары, кызыл; агач һәм ботак; йолдызлы күк; йөрәге шомлана; мәктәптә укыйбыз; бардым, катнаштым, әмма җиңмәдем.*

# Тикшерәбез!!!


| **Тезүле бәйләнеш** | **иярүле бәйләнеш** |
|---|---|
| Ручка, китап, дәфтәр һәм карандаш; | кибеттә очраштык; |
| курдем-танымадым; | йолдызлы күк; |
| зәңгәр, сары, кызыл; | йөрәге шомлана; |
| агач һәм ботак; | мәктәптә укыйбыз; |
| бардым, катнаштым, әмма җиңмәдем. | |

| **бишле** | **хатасыз** |
|---|---|
| дүртле | 1-2 хата |
| өчле | 3-4 хата |

# “Ирекле хат”...



**Ярдәмче сүзләр**: җыючы, ияртүле, бәйләнеш, хәбәрлекле мөнәсәбәт, тезүле, теркәгечле, теркәгечсез, каршы куючы, бүлүче, санау интонациясе, каршы кую интонациясе.




| | |
|---|---|
| **бишле** | **хатасыз** |
| дүртле | 1-2 хата |
| өчле | 3-4 хата |

# Хәбәрлекле мөнәсәбәт

Китап шкафта. Чәчәк сезгә. Мин Бакырчыдан.

Без тыңлыйбыз.

Алма тәмле.

Машина әтинеке.

Дәфтәр өстәл өстендә. Әниләр безнең белән.

Апам-кибетче.

**Хәбәрлекле мөнәсәбәтне барлыкка китерүче чаралар**

Юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килеше кушымчалары

Зат-сан куш-часы

Сүз тәртибе

Бәйлек, бәйлек сүзләр


-ныкы,-неке кушымчасы

Хәбәр итү интонациясе

# Хәбәрлекле мөнәсәбәт

- Бер сүз икенче сүз турында нәрсәдер хәбәр итә;
- Җөмлә барлыкка килә;
- 



# Унсигезенче октябрь.
# Хәбәрлекле мөнәсәбәт.
# 44нче күнегү.

**Яңгыр ява. Без-дуслар. Мин-укучы. Көн кояшлы. Җиләк күп. Кызлар килде. Әнием-табибә. Китап өстәлдә.**

| | |
|---|---|
| бишле | хатасыз |
| дүртле | 1-2 хата |
| өчле | 3-4 хата |

# “Ял итеп алыйк!”

# Текст белән эш:

Татфондбанк оештырган «Авылның сәләтле 100 баласы» акциясе күпләрне канатландыргандыр. Менә бит, ниһаять, авыл балаларына да үз сәләтен ачу мөмкинлеге туган! Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә уздырылучы бу чара берничә ел рәттән уздырылып килә.  Быел MasterCard халыкара түләү системасы да әлеге акцияне оештыруда үз өлешен керткән. Киләчәктә аңа башка оешмалар да кушылыр һәм әлеге чарада җиңүчеләр дә күбрәк булыр, дип ышанасы килә. Катнашучылар саны, елдан-ел артып, быел  850 кешегә җиткән. Киләсе елга ул тагын да артачак. Лаеклылар, һәрхәлдә, 100 генә түгел…

«Корстон»ның тамашалар залына Татарстанның барлык 43 районыннан  фән олимпиадаларында, төрле интеллектуаль бәйгеләрдә җиңү яулаган балалар җыелды. Чара башланганчы, кунаклар чәй эчеп ял итте, бер-берсе белән аралашты. Укучыларга Татфондбанкның индивидуаль дизайны  белән эшләнгән пластик карталар тапшырылды. Ел дәвамында шул пластик карталарга ай саен 1000 сум акча күчереләчәк. Үзенә күрә стипендия була инде.

Бу акция  сәләтле балаларны  барларга, аларга белем һәм рухи яктан үсәргә, камилләшергә ярдәм итә.


KORSTON
World Trade Center
КОРСТОН


АК БАРС БАНК
5209 3512 2580 0163
5209
MONTH/YEAR
VALID THRU 03/21
GULGUNA SHAFIGULLINA
BAKR OOSH 0114
MasterCard

# Биремнәрне үтибез:

1. **Сәләт, бәйге, рухи, камилләшергә** сүзләренең мәгънәләрен аңлатыгыз.

2. **Бу, акция, сәләтле, һәм, белем, ярдәм итә, үз, белән, күбрәк, елдан-ел** сүзләре кайсы сүз төркеменә карый?

3. **Тапшырырга, канатландырырга, артырга** сүзләренең синонимнарын табыгыз.

# Биремнәрне тикшерәбез:

1. **Сәләт-** **кешенең тумыштан ук килә торган нәрсәне булса да булдыру, яхшы эшләү.**

**Бәйге-ат чабышы, ярыш, көрәш, көч сынаш.**

**Рухи-эчке дөнья, психик сәләт, күңел, матди.**

**Камилләшергә –яхшырырга.**

2. **Бу-күр.алм., акция-исем, сәләтле-сыйф., һәм-теркәгеч, белем-исем, ярдәм итә-фигыль, үз-бил.алм., белән-бәйлек, күбрәк-рәвеш, елдан-ел-рәвеш.**

3. Тапшырырга-**бирергә**, канатландырырга-**шатландырырга**, артырга-**күбәергә**.

| | |
|---|---|
| Бишле | хатасыз |
| дүртле | 1-2 хата |
| өчле | 3-4 хата |

# Текст белән эш:

Татфондбанк оештырган «Авылның сәләтле 100 баласы» акциясе күпләрне канатландыргандыр. Менә бит, ниһаять, авыл балаларына да үз сәләтен ачу мөмкинлеге туган! Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәмендә уздырылучы бу чара берничә ел рәттән уздырылып килә.  Быел MasterCard халыкара түләү системасы да әлеге акцияне оештыруда үз өлешен керткән. Киләчәктә аңа башка оешмалар да кушылыр һәм әлеге чарада җиңүчеләр дә күбрәк булыр, дип ышанасы килә. Катнашучылар саны, елдан-ел артып, быел  850 кешегә җиткән. Киләсе елга ул тагын да артачак. Лаеклылар, һәрхәлдә, 100 генә түгел…

«Корстон»ның тамашалар залына Татарстанның барлык 43 районыннан  фән олимпиадаларында, төрле интеллектуаль бәйгеләрдә җиңү яулаган балалар җыелды. Чара башланганчы, кунаклар чәй эчеп ял итте, бер-берсе белән аралашты. Укучыларга Татфондбанкның индивидуаль дизайны  белән эшләнгән пластик карталар тапшырылды. Ел дәвамында шул пластик карталарга ай саен 1000 сум акча күчереләчәк. Үзенә күрә стипендия була инде.

Бу акция  сәләтле балаларны  барларга, аларга белем һәм рухи яктан үсәргә, камилләшергә ярдәм итә.

# *Тикшерәбез:

Акциясе канатландыргандыр. (Ачу)Мөмкинлеге туган. Чара уздырылып килә. Халыкара түләү системасы керткән. Оешмалар кушылыр. Җиңүчеләр булыр. Катнашучылар саны җиткән. Ул артачак. Лаеклылар түгел. Балалар җыелды. Кунаклар ял итте. Кунаклар аралашты. Карталар тапшырылды. Акча күчереләчәк. Стипендия була инде. Акция ярдәм итә.

# *Дәрес буенча Сезнең фикерләр…

* Хәбәрлекле мөнәсәбәтне җөмләдән таба беләм.
Әйе/юк
* Хәбәрлекле мөнәсәбәтне табуда кыенлык кичерәм.
Әйе\юк
* Тезүле бәйләнешкә хас үзлекләрне беләм.
Әйе\юк
* Ияртүле бәйләнешне тезүле бәйләнештән аера алмыйм.
Әйе\юк
* Дәрестә кайбер күнегүләрне аңлап бетермәдем.
(кайсыларын, язарга)____________________________

* Өй эше: 1-2. Кагыйдә-модель, бәйләүче чараларына мисаллар табарга.
* 3. 46нчы күнегү. “Талантның бер өлеше тумыштан, тугыз өлеше тырышлыктан”.